УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОДА КАЗАНИ
ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ ПО АВИАСТРОИТЕЛЬНОМУ И НОВО-САВИНОВСКОМУРАЙОНАМ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЦЕНТР ДЕТСКОГО ТВОРЧЕСТВА»
НОВО-САВИНОВСКОГО РАЙОНА г. КАЗАНИ

Принята на заседании
педагогического совета
Протокол № 1
от «02» 09 2022 года

«Утверждаю»
Директор МБУДО ЦДТ
_________ Медведева М.Н.
Приказ № 58 от «02» 09 2022 года

**ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ**
**ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА**
**«Тел күрке - сүз»**
**(Прелесть речи - слово)**
(на татарском языке)

**Направленность:** художественная
**возраст учащихся:** 7-16 лет
**срок реализации:** 3 года

**Автор-составитель:**
Якупова Сирина Алмазовна,
педагог дополнительного образования

**Казань - 2012**

## Эчтәлек

1. Пояснительная записка (на русском языке) ________________________________ 3 стр.

2. Аңлатма ________________________________________________________________ 6 бит

3. Беренче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы________ 10 бит

4. Икенче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы ________ 11 бит

5. Өченче уку елы программасының эчтәлеге һәм укыту-тематик планы ________ 13 бит

6. Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары ____________ 14 бит

7. Кулланылган әдәбият исемлеге __________________________________________ 14 бит

8. Кушымта _______________________________________________________________ 15 бит

**ОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ АДАПТИРОВАННАЯ ПРОГРАММА**
***«ТЕЛ КҮРКЕ - СҮЗ»***
***(Прелесть речи - слово)***

Данная программа является модифицированной. *Направленность программы*: художественная.

Настоящая программа разработана в соответствии с основными нормативными документами:

1. Федеральный закон об образовании в Российской Федерации от 29.12.2012 №273-ФЗ;
2. Распоряжение Правительства РФ от 31 марта 2022 г. N 678-р «Об утверждении Концепции развития дополнительного образования детей до 2030 г. и плана мероприятий по ее реализации»;
3. Федеральный проект «Успех каждого ребенка» в рамках Национального проекта «Образование», утвержденного Протоколом заседания президиума Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам от 3.09.2018 №10;
4. Приказ Минпроса России от 3.09.2019 №467 «Об утверждении Целевой модели развития региональных систем дополнительного образования детей»;
5. Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 9.11.2018 №196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»;
6. Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 23.08.2017 №816 «Об утверждении Порядка применения организациями, осуществляющими образовательную деятельность, электронного обучения, дистанционных образовательных технологий при реализации образовательных программ»;
7. СП 2.4. 3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденные Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 г. №28;
8. Устав образовательной организации.

*Форма реализации программы* – очная, в особых обстоятельствах допускается реализация образовательной программы или ее части с применением электронного обучения, дистанционных образовательных технологий. При электронном обучении с применением дистанционных образовательных технологий продолжительность занятия регулируется нормами СанПиН, принятых при работе учащихся за компьютером.

*Режим занятий:* Дети занимаются 2 раза в неделю по 1 академическому часу. Всего на год отводится 72 часа. При электронном обучении с применением дистанционных образовательных технологий продолжительность занятия регулируется нормами СанПиН, принятых при работе учащихся за компьютером.

*Срок реализации программы* – программа рассчитана на занятия со школьниками от 7 лет и разработана на 3 года, 216 часов. Занятия проводятся 2 раза в неделю по 1 часу. Всего 72 часа в год. Количественный состав группы – не более 15 человек. В объединение принимаются по желанию, независимо от способностей. Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа реализуется в течение всего календарного года, включая каникулярное время. При выполнении дополнительной общеобразовательной общеразвивающей программы организуется работа в пришкольных лагерях, проводятся воспитательно-образовательные мероприятия.

*Новизна программы* заключается в том, что она составлена с учетом возрастных особенностей детей, желанием проявить себя в творческой деятельности, что повышает мотивацию изучения татарского, русского языков, а также, нашего опыта в том, что он позволяет осуществить перенос учебных знаний на практику, в ситуации, в которых организуется речевое свободное общение.

*Актуальность:* Влияние любого вида искусства, в т. ч. и такого как художественное чтение, на личность ребенка неоспоримо. Формирование нравственных начал происходит через работу и в качестве самодеятельного исполнителя, и в качестве активного театрального зрителя. Это в свою очередь способствует саморазвитию личности ребенка, обогащает его духовный и нравственный мир, формирует активную жизненную позицию. Все это и делает программу актуальной на сегодняшний день.

*Педагогическая целесообразность*: Художественно-эстетическое образование детей средствами художественного слова способствует решению ряда учебных задач: обучению живой разговорной речи, приобретению известной свободы в обращении, умению выступать перед аудиторией в качестве ораторов. формирует мировоззрение, эстетический вкус, пробуждает самостоятельное и независимое мышление

***Цель:*** развитие творческих, духовно- нравственных, интеллектуальных качеств детей, обогащение знаниями, повышающими внутреннюю и внешнюю культуру, через приобщение к миру искусства.

***Задачи:***

*Образовательные:*

- умение разбирать художественное произведение
- умение действенно выполнять намеченную задачу
- умение давать характеристику героев произведения
- умение выразительно читать наизусть
- анализировать и оценивать образцы художественного слова как художественное и эстетическое целое;
- совершенствовать речь, дикцию

*Развивающие:*

- развитие творческого мышления, развитие художественно-творческих способностей учащихся
- развитие навыков общения
- развитие воображения и наблюдательности
- создание условий, позволяющих детям найти свое место в творчестве

*Воспитывающие:*

- воспитание любви и интереса к культуре Отечества и мировой культуре
- воспитание эстетической культуры детей

Основа обучения – чтение и изучение художественных произведений, знакомство с изобразительно-выразительными средствами языка художественной литературы, формирование навыка выразительного чтения.

***Ожидаемые результаты:***

К концу ***первого года*** обучения дети должны

*знать:*

- историю развития жанра художественного чтения;
- современных мастеров литературной эстрады;
- что такое сверхзадача литературного произведения и сверхзадача исполнителя;

*уметь:*

- подготовить самостоятельно артикуляционный и голосовой аппарат к звучанию;
- самостоятельно осуществлять выбор художественного произведения и обосновывать свой выбор;
- осуществлять разбор художественного произведения: идея, основная мысль, сверхзадача, стилистика автора, художественные особенности произведения, герои и их характеристика, взаимоотношения и поступки, событийный ряд;

К концу ***второго года*** обучения дети должны

*знать:*

- художественные особенности литературного произведения;
- законы логического разбора произведения;

- элементы актерского мастерства: оценка факта; речевая характеристика героев;
- законы орфоэпии;

*уметь:*

- придумать речевую характеристику героев;
- воплотить литературное произведение в звучащем слове;
- подготовить к творческому отчету тематический цикл произведений одного или разных авторов (не менее 5 произведений).

К концу ***третьго года*** обучения дети должны

*знать:*

- приёмы работы с партнёром;
- понятия «жанр, «идея», сверхзадача», «конфликт»;
  - *уметь:*
- пересказывать большой текст близко к оригиналу;
- самостоятельно работать с текстом;
- действовать в предлагаемых обстоятельствах с импровизированным текстом на заданную тему;
- сочинять индивидуальный или групповой этюд на заданную тему;
- самостоятельно делать презентации по теме «Мастера художественного чтения»;
- подбирать музыкально оформление к стихам литературной композиции.
- составлять монолог и диалог;
- самостоятельно записать 10 коротких диалогов, взятых из жизни: определить конфликт, речевое действие, характеры героев, отношение их друг к другу;
- самостоятельно работать над прозой;
- самостоятельно работать над стихами, басней;
- самостоятельно выбирать чтецкий материал;
- сочинять небольшую сказку, рассказ;
- готовить к творческому отчету тематический цикл произведений одного или разных авторов (не менее 10 произведений).

**Возрастные особенности категорий учащихся**

Дети 10 – 12 лет.

Для детей этой группы важен оптимистический настрой учебно-воспитательного процесса, поэтому основными формами занятий являются: занятие-игра, путешествие, конкурс, сюжетные, ролевые и развивающие игры, этюды на фантазию. Учащиеся инициативны, с ярким воображением, «легки на подъём», чётко ограничивают понятия «добро» и «зло», они с интересом работают над такими художественными произведениями, как сказки, весёлые стихи, истории на школьную тему, где добро побеждает зло.

С удовольствием принимают участие в конкурсно-игровых программах.

Дети 13–15 лет.

Важной потребностью этой возрастной группы учащихся является потребность эмоционального самовыражения и взаимодействия, они учатся активной деятельности. Значительно развивается логическое мышление, сильно чувство команды. Любят рассказы, истории о смелых, дерзких людях. Поэтому, подбирая чтецкий материал для этой группы, надо опираться на данные качества учащихся. Эта возрастная группа стремится к соревновательности, чаще других принимает участие в различных конкурсах и фестивалях.

Дети готовы к выполнению самостоятельных заданий, например:

- придумать и разыграть этюды с диалогом;
- сочинить свои скороговорки, сказки, рассказы;
- придумать свою концовку всем известной сказки и т. д.

Подростки 16–17 лет.

Этот возраст является периодом формирования самосознания и собственного мировоззрения, этапом начала принятия ответственных решений. Это время, когда ценности дружбы, любви, становятся первостепенными. Появляется стремление заново и критически осмыслить все окружающее, самоутвердится, создать собственные теории смысла жизни, любви, счастья. Учащиеся этой возрастной группы с интересом работают над отрывками художественных произведений, где затрагивается тема любви, отношений, выполняют самостоятельные задания:
- выбрать чтецкий материал и самостоятельно работать над ним;
- придумать рассказ, сказку и записать её;
- «работать» педагогом с учащимися младших групп;
- разыгрывать этюды «Я в предлагаемых ситуациях с использованием монолога».

**Особенности организации образовательного процесса.**

В образовательном процессе используются фронтальная, групповая и индивидуальные формы обучения.

- образовательный процесс организован в соответствии с учебным планом в объединении «Художественное слово»;
- методика организации образовательного процесса нацелена на то, чтобы учащийся открывал в себе автора: стихов, прозы, басни, скороговорок и т. д.;
- приветствуется самостоятельный, свободный выбор учащимися чтецкого материала и самостоятельная работа над ним;
- большое внимание уделяется совместной коллективной деятельности: праздники, КИП, викторины;
- на занятиях используются пословицы, поговорки, крылатые выражения, что позволяет разнообразить занятия, снять утомление, пополнить словарный запас учащихся;

Программа предусматривает широкое использование таких приемов обучения, как:
- театральные игры,
- разыгрывание ролей,
- проблемное практическое задание,
- анализ конкретных ситуаций, поисковый.

При проведении итогов занятий применяются методы контроля и коррекции: взаимопроверка, рефлексия (театральные маски, смайлики, карточки «радуга» и т. д.).

**Аңлатма.**

Нәфис сүз сәнгате – әдәби әсәрнең хәрәкәттә, яңгыраган сүздәге иҗади чагылышы. Балаларны сәнгатьле уку спецификасы белән бәйләнгән күпкырлы эшчәнлеккә тарту аларның сәләтләренең төрле яклап үсешенә зур мөмкинлекләр ача. Ул баланың рухи яктан баюына, шәхес буларак формалашуы һәм үсешенә этәргеч булып тора.

Программа 2012 нче елның 29нчы декабрендә чыккан “Рәсәй Федерациясендә белем бирү турындагы” (№273-ФЗ 29.12.2012)Федераль Законга, Рәсәй Федерациясенең “Белем бирү үсеше” Дәүләт программасы (2013-2020нче елларга), РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча укыту эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турындагы” карары (№1008 29.08.2013), Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар СанПиН 2.4.3172-14(Рәсәйнең ЮстМин-да 2014нче елның 20нче августында теркәлгән №33660), 2014-2020нче елларга балаларга өстәмә белем бирү үсеше Концепциясе (РФ Хөкүмәте күрсәтмәсе нигезендә №1726-р 2014елның 4нче сентябреннән), РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының“ Өстәмә тулаем үсеш бирүче программаларын (төрле дәрәҗәдәгеләрен дә кертеп) проектлаштыру буенча методик рекомендацияләрнең юнәлешләре турындагы” (18.11.2015) Хат, РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының Яшьләр сәясәте, балаларны тәрбияләү һәм социаль яклау. Балалар иҗат үзәге Уставына нигезләнеп эшләнгән.

Әдәби әсәрне сәнгатьле укуның ***бурычы*** булып - тыңлаучыларның күзаллауларында автор иҗат иткән тормыш күренешләрен тулысынча тудыра белү, эзлекле, бер- берсенә

бәйле рәвештә аларда ачылып баручы мәгънә һәм идеяләрне аерып күрсәтү, яңгыраучы сүздә автор стиленең үзенчәлекләрен җиткерү тора.

Әсәрдә күрсәтелгән күренешләрнең мәгънәсен аңлау, аларга карата эмоциональ мөнәсәбәт һәм әлеге мәгънәне тизрәк тыңлаучыларга җиткерергә омтылыш – интонация, темп, тавышның тембрлы үзгәрешләренең күптөрлелек чыганагы.

Интонация – укучының уй-фикерләре, мөнәсәбәте, ниятләренең нәтиҗәсе ул. Шуңа күрә тавышка ияртеп интонациягә өйрәтү дөрес саналмый. Механик рәвештә педагогның интонациясен кабатлау баланы укыган нәрсәнең мәгънәсенә төшенү, мөстәкыйль фикер йөртү һәм яңгыраган текстны бәяләү ихтыяҗыннан мәхрүм итә.

Текстта сөйләнелгән нәрсәне ачык итеп күзаллый алу хыялның актив эшен таләп итә. Сәнгатьле уку дәресләрендә хыялның үзен үстерү кирәк булган кебек, хыяллану өчен материал бирүче күзәтүчәнлек тә бик мөһим, шулай ук билгеләнгән максатка ирешүне тәрбияләү дә бик зарур. Әлеге сыйфатларны, сәләт һәм күнекмәләрне тәрбияләү өчен, тиешле күнегүләр кулланып, махсус вакыт билгеләргә кирәк. Зур булмаган һәм гади текстлар моның өчен материал булып хезмәт итә.

***Программаның юнәлеше*:** сәнгати-эстетик.

***Программаның яңалыгы*** , аның балаларның яшь үзенчәлекләрен, ни дәрәҗәдә иҗади эшчәнлектә үз-үзләрен күрсәтергә теләүләрен исәпкә алып төзелүендә. Бу, үз чиратында, татар, рус телләрен өйрәнергә булган мотивацияне күтәрә, шулай ук, иркен аралашу, сөйләм оештырылу ситуацияләрендә аң-белемне практикага күчерүне тормышка ашырырга мөмкинлек тудыра.

***Актуальлеге:*** Бала шәхесенә, сәнгатьнең теләсә кайсы төре кебек үк нәфис сүзнең дә йогынтысы булуы бәхәссез.

Әхлакый башлангычның формалашуы, үзешчән башкаручы сыйфатындагымы яисә актив театраль тамашачы сыйфатындагымы хезмәт аша барлыкка килә. Бу, үз чиратында, бала шәхесенең үзүсешенә ярдәм итә, аның рухи һәм әхлакый дөньясын баета, актив тормыш позициясен формалаштыра. Болар барысы бергә программаны бүгенге көндә актуаль итә дә инде.

***Педагогик максатчанлык*:** Нәфис сүз алымнары белән балаларга сәнгати-эстетик белем бирү күп кенә укыту мәсьәләләрен чишәргә ярдәм итә: тере сөйләм теленә өйрәтү, мөрәҗәгать итүдә билгеле бер иркенлеккә ирешү, аудитория каршында оратор сыйфатында чыгыш ясый белү, дөньяга караш, эстетик зәвык формалаштыра, мөстәкыйль, бәйсез фикерләү барлыкка китерә.

***Әлеге укыту программасын аерып торучы үзенчәлекләр:*** Дәресләрне төзегәндә кечкенә төркемнәрдә эшләү кулланыла, бу исә барлык балаларга да төрле позицияләрдә катнашырга мөмкинлек бирә: лидерлыкның, “педагог-тәрбияләнүче” роль функцияләренең алмашынуы. Укыту эшчәнлеге, проблемалы ситуацияне тудырып һәм чишеп, балалар бер-берсен үзара өйрәтерлек, мәгълүмат белән алмашырлык итеп оештырылган. Балалар бер-берсенең чыгышына төрле тренинглар, уеннар аша бәя бирәләр. Мөстәкыйльэшкә зур игътибар бирелә.

***Максат:*** балаларның иҗади, рухый-әхлакый, интеллектуаль сыйфатларын үстерү, сәнгать дөньясына тарту аша эчке һәм тышкы культураларын баетучы аң-белемнәр бирү.

***Максатлар:***

*Белем бирү:*

- әдәби әсәрне тикшерә белү;
- билгеләнгән мәсьәләне хәрәкәти үтәү;
- әсәрдәге геройларга характеристика бирә белү;
- сәнгатьле итеп яттан сөйли белү;
- сәнгати һәм эстетик бербөтен буларак нәфис сүз үрнәкләрен анализлый һәм бәяли белү;
- сөйләмне, дикцияне камилләштерү.

*Акыл сәләтен үстерү:*

- иҗади фикерләүне үстерү, укучыларның сәнгати-иҗади сәләтләрен арттыру;
- аралашу күнекмәләрен үстерү;
- хыяллану һәм күзәтүчәнлекне үстерү;
- иҗатта балаларга үз урыннарын табарга мөмкинлек бирүче шартлар тудыру.

*Тәрбияви:*

- дөнья һәм Ватан мәдәниятына мәхәббәт һәм кызыксыну тәрбияләү;
- балаларда эстетик мәдәният тәрбияләү.

Берләшмәгә теләге булган 7-16 яшьлек барлык балалар да кабул ителә. Балалар атнага 1 сәгать шөгыльләнәләр. Барлыгы елга 72 сәгать. Группада балалар саны 15 тән артмаска тиеш. Берләшмәгә балалар сәләтенә бәйсез рәвештә, теләк буенча алына.

***Программы реализацияләү вакыты*:**

Программаны тормышка ашыру вакыты - 3 ел. Укытуның нигезе – әдәби әсәрләрне уку һәм өйрәнү, матур әдәбият теленең сурәтләү-тәэсири чаралары белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен формалаштыру.

Уку даирәсенең киңәюе һәм яттан сәнгатьле сөйләү дәрәҗәсе күтәрелү, әдәби әсәрнең төбенә тирәнтен төшенү һәм аны кабул итү курс укытуның нигезен тотып торучы мөһим чарага әверелде. Иң яхшы нәфис сүз үрнәкләре белән эш кызыклы, уйланылган, балаларның акылына һәм күңеленә тәэсир итәрлек булсын өчен, укучыларны эмоциональ кабул итәргә, әдәби әсәрне дөрес итеп анализлый белергә өйрәтү, укуга ихтыяҗ тудыру зарур.

Сәнгатьле уку берләшмәсенең программасында ике бүлекне аерып карарга кирәк: 1)әдәби әсәрне башкару өстендә эш – әсәрне тикшерү, аны яңгыраган сүздә тормышка ашыру, башкару буенча фикер алышу; 2)сәнгатьле уку өчен кирәкле булган сыйфатлар һәм күнекмәләр тәрбияләү. Сәнгатьле уку берләшмәсендә һәр уку елы саен эшнең катлаулана баруы программаның киңәюе , укучылардан теге яки бу өстәмә сыйфат, сәләтләр таләп итүче яңа бүлекләр өстәлү белән түгел, ә бәлки әдәби әсәрне тикшерү һәм башкару дәрәҗәсенә карата таләпләрнең табигый артуы белән билгеләнә. Бу таләпләрнең артуы кулланылган материалның катлаулануы, иң мөһиме, берләшмәдәге балаларның яше һәм үсеше белән тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә аларның һәрберсенең индивидуаль үзенчәлекләрен күздә тотып тормышка ашырыла. Шуңа бәйле рәвештә, программада беренче ел өчен күрсәтелгән таләпләр һәр уку елы өчен мәҗбүри булып кала. Башкару сыйфатына карата һәр уку елы саен булган таләпләрне регламентлау мөмкин түгел. Алар һәрвакыт укучыларның индивидуаль үзенчәлекләренә бәйләнгән һәм шуңа ярашлы рәвештә дифференцияцияләнәләр.

Сөйләмнең төгәл һәм ачык булуын тәэмин итүче сөйләм техникасына караган дәресләр балалар белән, бигрәк тә башта, четерекле һәм зур, чын тренировка эшен таләп итә.

Төп вакыт әдәби әсәр яки өзекләрне башкару өстендәге эшкә бүленеп бирелә. Бу процесс эчендә укучылар аңа карата булган барлык таләпләр берлегендә, нәфис сүз сәнгатен тулаем үзләштерәләр. Һәр баланың укуы буенча җентекле фикер алышу бик зур файда китерә. Мондый фикер алышулар башкаручыны тыңларга өйрәтә, игътибарлылык тәрбияли, башкару сыйфатына карата сәнгати бәя критерияләрен формалаштыра, иптәшләр тәнкыйтенә ияләштерә, коллективны берләштерә. Башкару өчен сайлап алынган әсәрләр югары сәнгати сыйфатлары белән аерылып торырга, балалар күңеленә үтеп керерлек һәм аңлаешлы булырга тиешләр. Башкару өчен әсәрләрне сайлауда балалардан үзләренә һәм иптәшләренә карата инициатива күрсәтүне таләп итү мөһим.Бу аларны күп итеп һәм аңлап укырга өйрәтә. Дәресләр яңгыраучы сүзгә һәм әдәбиятка карата кызыксынуны арттыра, түгәрәктә йөрүчеләрдә сәнгати зәвык тәрбияли.Тыңлаучылар каршында чыгыш ясау перспективасы берләшмәдәге дәресләргә кызыксыну уята.Шулай да, чыгыш ясаулар еш булырга тиеш түгел. Югыйсә, балаларда үз башкаруына карата булган таләпләрнең дәрәҗәсе кимү котылгысыз. Һәр бала тыңлаучылар каршындагы үз чыгышларына җаваплылык белән карарга, хәзерлек чорында бик каты эшләргә өйрәнергә,

ә инде чыгыш ясауны шатлыклы, шул ук вакытта бик җитди һәм җаваплы мәсьәлә итеп кабул итәргә тиеш.

*Дәреслрәнең режимы һәм формалары.* Дәресләр бөтен состав, подгруппа белән һәм индивидуаль формада уздырылырга мөмкин.Дәрес барышында укытуның төрле алымнары аралаштырыла: әңгәмә, күнегүләр, уен-этюдлар, төрле язмалар тыңлау, видеоматериаллар карау.

Өстәмә гомуми белем бирү гомуми акыл үсешен үстерү программасы, каникуляр вакытларны да үз эченә алып, барлык календарь ел дәвамында тормышка ашырыла. Әлеге программаны үтәү барышында мәктәп яны лагерьларында эш оештырыла, күңел ачу-белем бирү спорт мероприятиеләре үткәрелә.

*Көтелгән нәтиҗәләр:*

1. Балалар берләшмәсенә йөрүчеләр үзләрен иркен хис итә.
2. Сөйләм техникасы буенча алган белемнәрен , башкаручының әсәр өстендәге эш этапларын грамоталы куллана беләләр.
3. Әдәби әсәрләрне анализлый беләләр.
4. Актёрлык сәнгатьлелеге элементларына ия.
5. Этик мәсьәләләрдә ориентлашалар, белемгә һәм матурлыкка омтылалар.
6. Коллективтагы хезмәтне бәяли беләләр.
7. Балалар автор тасвирламасына яраклы рәвештә, әсәрдә күрсәтелгән тормыш күренешләрен ачык һәм конкретрак итеп күз алдына китерергә өйрәнәләр.
8. Үзләренең укулары аша автор фикерен логик яктан дөрес һәм төгәл итеп җиткерә, текстның мәгънәсен аерып күрсәтә беләләр.
9. Әсәрнең сәнгати үзенчәлеген, язучының осталыгын сиземләү һәм бәяли белү сәләте арта.
10. Иптәшләре уку барышында җибәргән хаталарны ишетә һәм тикшерә белү сәләте ныгытыла.

Программа эчтәлегенең мәҗбүри минимумын үзләштерү нәтиҗәсендә укучылар

*Белергә тиеш:*

- Әдәби әсәр төрләре.
- Әсәрдә автор кулланган сәнгати-тасвирлама чаралары.
- Логик уку кагыйдәләре.
- Шигъри тел үзенчәлекләре.
- Әсәрнең жанр үзенчәлекләре.
- Нәфис сүз осталары башкаруындагы рус һәм татар классик әсәрләре.

*Булдыра белергә:*

- Уку һәм текстуаль өйрәнүгә билгеләнгән әдәби әсәрләрне укый.
- Сәнгати һәм эстетик бербөтен буларак,нәфис сүз үрнәкләрен анализлый һәм бәяли белергә.
- Әсәргә шәхсән бәя бирә белергә.
- Әдәбият белеме төшенчәләрен танып белергә.
- Яттан сәнгатьле укый белергә.
- Сөйләм, дикцияне камилләштерергә.
- Язарга, “каләм тибрәтергә” омтылып карарга.

<u>Нәтиҗәләр чыгару һәм контроль формалары:</u>

Әлеге программаны тулаем тормышка ашыру өчен төрле контроль чаралары кулланыла:

- агымдагы – дәресләр вакытында баланың эшчәнлеге артыннан күзәтү юлы белән тормышка ашырыла;
- ара-ара – өстәмә белем бирү учреждениеләрендә уздырылучы тестлар, бәйрәмнәр, бәйгеләр;
- йомгаклау – ачык занятиеләр, концерт, фестивальләр.

***Укытуның 1нче елы***

| №<br>п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *Теория* | *Практика* | *Всего* | |
| 1 | Кереш | 1 | 1 | 2 | |
| 2 | Сөйләм техникасы нигезләре | 2 | 12 | 14 | |
| 3 | Әсәрне тикшерү | 6 | 8 | 14 | |
| 4 | Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү | 6 | 16 | 22 | |
| 5 | Сәнгатьле уку нигезләре | 6 | 12 | 18 | |
| 6 | Контроль дәрес | 1 | 1 | 2 | |
| | Барлыгы | 22 | 50 | 72 | |

***Беренче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш – 2 с.**

Аралашу, тәэсир итү чарасы буларак сөйләм. Сөйләм теле һәм нәфис сүз.Җанлы аралашу процессында тыңлаучыларга тәэсир итү чарасы буларак нәфис сүз. Сәхнә сәнгатендә мөстәкыйль жанр буларак нәфис сүз. Рәсәйдә нәфис сүзнең тарих битләре.Хикәятчеләр. Драматизаторлар. Нәфис сүз жанрында беренче чыгыш ясаучылар. А. Я. Закушняк, П. П. Гайдебуров

**Тема 2. Сөйләм техникасы нигезләре - 14 с.**

*Теория.*

Аваз туу. Сөйләм аппаратының анатомиясе һәм физиологиясе турында кыскача мәгълүмат. Сөйләм аппараты бүлекләре. Сулыш алу системасы. Сөйләм аппараты гигиенасы. Сулыш алу һәм тавыш. Сулыш алу һәм аваз. Дикция. Артикуляцион гимнастика һәм аның әһәмияте. Сузык авазлар. Тартыкларны классификацияләү. Орфоэпия- дөрес сөйләм, сүзләрнең әйтелеш нормалары. Әдәби әйтелеш нормасы. Орфоэпиядә басым роле.Тыныш билгеләр. “Диапазон”, “регистр”( тавышның югарылык дәрәҗәсе), “ Тыныш билгеләрне тональ чагылдыру” төшенчәләре. Аралашу телендә интонация кануннары. Гади һәм катлаулы җөмләләр. Сөйләм темпы. Сөйләм ритмы. Сөйләм логикасы.

*Практика.*

1. Тын чыгару белән идарә итү сәләтен эшкәртүгә күнегүләр.

Сулыш алуда катнашучы мускулларны күнектерү өчен күнегүләр.

2. Артикуляцион гимнастика күнегүләре. Дикция буенча күнегүләр комплексы.Сузык һәм тартык авазларның әйтелешен эшкәртү. Күнектерелүче авазның сузык авазлар белән туры килүенә караган күнегү. Тизәйткеч текстлары белән күнегүләр.

3. Сүзлек белән эш.Басымны тикшерү. Сүзләрдә авазлар кушылмасының(сочетание) әйтелеше.

4. “Талантлар калейдоскобы ”. Иҗади уен

**Тема 3. Әсәрне тикшерү– 14 с.**

Әсәрнең төре (әкият, хикәят,мәсәл, хикәя, шигырь).

Әсәрнең язылу вакыты.

Әсәр геройларына җентекле характеристика .

Әсәрнең сюжеты үсү дәрәҗәсенә карап катнашучыларның холкы һәм тәртипләрендәге үзгәрешләр, һәр катнашучының максат һәм исәпләре.Әсәр бүлекләренең үзара бәйләнеше.

Әсәрдә автор кулланган сәнгати-тасвирлама чаралар.
*Практик дәрес.* Татар халык әкиятен сәнгатьле уку.

**Тема 4. Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү - 22 с.**

Тыңлаучыларга конкрет тәэсир итү өчен башкару максатларын үтәү. Укуда текстта чагылдырылган уй-фикерләр, мөнәсәбәт һәм исәп-ниятләрен җиткерү(подтекстны тапшыру).
Эпоха әсәрендә чагылдырылган шул чорның көнкүреш үзенчәлекләрен, кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары һәм үзара мөнәсәбәтләрен хыялда тудыру(күз алдына китерү).
Логик укуның кагыйдәләрен үтәү(паузалар, басым, логик перспектива).
Шигъри телнең үзенчәлекләрен(ритм, рифма) ачыклау.
Юл паузаларының, логик яисә психологик басым булмасын, үтәлеше.
Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен ачыклау.
*Практик дәрес*. Прозаик тексттан өзекне сәнгатьле уку.
Конкурс-дәрес. Минем яраткан шигырем.

**Тема 5. Сәнгатьле уку нигезләре - 18 с.**

Шигъри әсәр һәм аның өстендә эшләүнең үзенчәлекләре. Башкару методлары. Башкару төзелеше : пафос, хикәяләү.
Актерлык һәм нәфис сүз сәнгатендә сүз тәэсиренең уртак нигезләре һәм сәхнә үзенчәлекләре.
*Практика*
Әсәрне сайлауда нигезләү, дәлилләү.Башкаручының параметрларының сайланган әсәргә туры килүе(Фикер алышырга).Әсәрне тикшерү, сөйләм логикасы.Интонацион сурәтләү элементлары.Басым. Паузалар: логик, психологик, шигырьара, цезур, ритмик.Сөйләм мелодикасы. Пластик сәнгатьлелек. Жестлар: ирексез, ритмик, иллюстратив, подтекстлы.
Әдәби композиция тудыру принциплары. Композиция төрләре. Әдәби композициянең архитектоникасы. Композициядә музыка . Композиция өстендә эш.Әсәрләр өстендә эш. Мәктәп концертларын алып баручылар белән эш.
Укуда әсәрнең жанр үзенчәлеген һәм геройларның үз-үзләрен тоту мотивларын төгәл ачыкламауны күреп алу сәләтен тәрбияләү.
*Практик дәрес*. Телдән сүз белән сурәтләү. Үз оригиналь текстыңны тудыру.

**Тема 6. Йомгаклау дәресе –2 с.** .Концерт – чыгыш ясау.

***Укытуның 2-нче елы.***

| № п/п | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *Теория* | *Практика* | *Всего* | |
| 1 | Кереш | 1 | 1 | 2 | |
| 2 | Сөйләм техникасы нигезләре | 2 | 12 | 14 | |
| 3 | Әсәрне тикшерү | 8 | 8 | 16 | |
| 4 | Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү | 12 | 8 | 20 | |
| 5 | Сәнгатьле уку нигезләре | 4 | 14 | 18 | |
| 6 | Йомгаклау дәресе | 1 | 1 | 2 | |
| | Барлыгы | 28 | 44 | 72 | |

***Икенче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш - 2сәг.**

Аралашу, тәэсир итү чарасы буларак сөйләм. Сөйләм теле һәм нәфис сүз.Җанлы аралашу процессында тыңлаучыларга тәэсир итү чарасы буларак нәфис сүз. Сәхнә сәнгатендә мөстәкыйль жанр буларак нәфис сүз. Рәсәйдә нәфис сүзнең тарих битләре.Хикәятчеләр.

Драматизаторлар. Нәфис сүз жанрында беренче чыгыш ясаучылар. А. Я. Закушняк, П. П. Гайдебуров

**Тема 2. Сөйләм техникасы нигезләре - 14 с.**

*Теория.*

Аваз туу. Сөйләм аппаратының анатомиясе һәм физиологиясе турында кыскача мәгълүмат. Сөйләм аппараты бүлекләре. Сулыш алу системасы. Сөйләм аппараты гигиенасы. Сулыш алу һәм тавыш. Сулыш алу һәм аваз. Дикция. Артикуляцион гимнастика һәм аның әһәмияте. Сузык авазлар. Тартыкларны классификацияләү. Орфоэпия- дөрес сөйләм, сүзләрнең әйтелеш нормалары. Әдәби әйтелеш нормасы. Орфоэпиядә басым роле.Тыныш билгеләр. “Диапазон”, “регистр”( тавышның югарылык дәрәҗәсе), “ Тыныш билгеләрне тональ чагылдыру” төшенчәләре. Аралашу телендә интонация кануннары. Гади һәм катлаулы җөмләләр. Сөйләм темпы. Сөйләм ритмы. Сөйләм логикасы.

*Практика.*

1. Тын чыгару белән идарә итү сәләтен эшкәртүгә күнегүләр.

Сулыш алуда катнашучы мускулларны күнектерү өчен күнегүләр.

2. Артикуляцион гимнастика күнегүләре. Дикция буенча күнегүләр комплексы.Сузык һәм тартык авазларның әйтелешен эшкәртү. Күнектерелүче авазның сузык авазлар белән туры килүенә караган күнегү. Тизәйткеч текстлары белән күнегүләр.

3. Сүзлек белән эш.Басымны тикшерү. Сүзләрдә авазлар кушылмасының(сочетание) әйтелеше.

**Тема 3. Әсәрне тикшерү– 14 сәг.**

Әсәрнең төре (әкият, хикәят,мәсәл, хикәя, шигырь). Әсәрнең язылу вакыты. Әсәр геройларына җентекле характеристика. Әсәрнең сюжеты үсү дәрәҗәсенә карап катнашучыларның холкы һәм тәртипләрендәге үзгәрешләр, һәр катнашучының максат һәм исәпләре.Әсәр бүлекләренең үзара бәйләнеше. Әсәрдә автор кулланган сәнгати-тасвирлама чаралар.

*Практик дәрес.* Татар халык әкиятен сәнгатьле уку.

**Тема 4. Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү - 22 сәг.**

Тыңлаучыларга конкрет тәэсир итү өчен башкару максатларын үтәү. Укуда текстта чагылдырылган уй-фикерләр, мөнәсәбәт һәм исәп-ниятләрен җиткерү(подтекстны тапшыру).

Эпоха әсәрендә чагылдырылган шул чорның көнкүреш үзенчәлекләрен, кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары һәм үзара мөнәсәбәтләрен хыялда тудыру(күз алдына китерү).

Логик укуның кагыйдәләрен үтәү(паузалар, басым, логик перспектива).

Шигъри телнең үзенчәлекләрен(ритм, рифма) ачыклау.

Юл паузаларының, логик яисә психологик басым булмасын, үтәлеше.

Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен ачыклау.

*Практик дәрес*. Прозаик тексттан өзекне сәнгатьле уку.

Конкурс-дәрес. Минем яраткан шигырем.

**Тема 5. Сәнгатьле уку нигезләре - 18 сәг.**

Шигъри әсәр һәм аның өстендә эшләүнең үзенчәлекләре. Башкару методлары. Башкару төзелеше : пафос, хикәяләү.

Актерлык һәм нәфис сүз сәнгатендә сүз тәэсиренең уртак нигезләре һәм сәхнә үзенчәлекләре.

*Практика*

Әсәрне сайлауда нигезләү, дәлилләү.Башкаручының параметрларының сайланган әсәргә туры килүе(Фикер алышырга).Әсәрне тикшерү, сөйләм логикасы.Интонацион сурәтләү элементлары.Басым. Паузалар: логик, психологик, шигырьара, цезур, ритмик. Сөйләм мелодикасы. Пластик сәнгатьлелек. Жестлар: ирексез, ритмик, иллюстратив, подтекстлы. Әдәби композиция тудыру принциплары. Композиция төрләре. Әдәби композициянең архитектоникасы. Композициядә музыка . Композиция өстендә эш.Әсәрләр өстендә эш.

Мәктәп концертларын алып баручылар белән эш. Укуда әсәрнең жанр үзенчәлеген һәм геройларның үз-үзләрен тоту мотивларын төгәл ачыкламауны күреп алу сәләтен тәрбияләү.

_Практик дәрес_. Телдән сүз белән сурәтләү. Үз оригиналь текстыңны тудыру.

**Тема 6. Йомгаклау дәресе –2 сәг.** .Концерт – чыгыш ясау.

***Укытуның 3нче елы***

| № | Наименование раздела, темы | Количество часов | | | Формы промежуточной аттестации/ контроля |
|---|---|---|---|---|---|
| | | *Теория* | *Практика* | *Всего* | |
| 1 | Кереш | 1 | 1 | 2 | |
| 2 | Әсәрне тикшерү | 6 | 8 | 14 | |
| 3 | Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү | 4 | 14 | 18 | |
| 4 | Башкару буенча фикер алышу | 2 | 4 | 6 | |
| 5 | Сәнгатьле уку өчен кирәкле булган сыйфат, сәләт, күнекмәләрне тәрбияләү | 4 | 16 | 20 | |
| 6 | Практик дәресләр | 2 | 8 | 10 | |
| 7 | Йомгаклау | 1 | 1 | 2 | |
| | Барлыгы | 20 | 52 | 72 | |

***Өченче уку елы программасының эчтәлеге.***

**Тема 1. Кереш -2 сәг.**

Сөйләм теленең бер формасы буларак нәфис сүз. (монологик). Автор һәм тыңлаучы арасындагы арадашчы буларак башкаручының роле. Башкаручының максаты: әдәби әсәрне төрле яклап һәм тирәнтен өйрәнгәннән соң, тыңлаучыларга тиешле йогынты ясау максаты белән авторның текстта яшеренгән уй-фикерләре, ниятләрен, әсәрдә сурәтләнгән тормышка карата мөнәсәбәте һәм бәясен ачыклау.

**Тема 2. Әсәрне тикшерү – 14 сәг.**

Авторны әлеге әсәрне язуга этәргән сәбәпләр.Әсәрдә сурәтләнгән эпоха. Язучының дөньяга карашы.

Әсәр геройларын камап алган мохитка характеристика . Әсәрнең тема һәм идеясы.

Әсәрнең композициясе.

Автор стиленең үзенчәлекләре.

**Практик дәрес**. Әсәргә анализ.Драматик әсәрне сәнгатьле уку.

**Тема 3. Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү - 18 сәг.**

Башкару максатының сәнгатьле укуның һәр бүлеге– сәнгати образларның яңгыраучы сүздә яңабаштан тууы һәм тыңлаучыга аерым бер тәэсир итүче әсәр идеясын ачыклауга буйсынуы. Укуда автор тарафыннан сурәтләнгән чынбарлыкка карата үз мөнәсәбәтеңне, үз бәяңне җиткерү.

Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен, автор стилен ачыклау. Хикәяләүче образы.

**Тема 4. Башкару буенча фикер алышу -6 сәг.**

Әсәрнең аерым өлешләре арасында бәйләнеш юклыгын ишетә, аерым вакыйга һәм эпизодларның әһәмиятлелеген бәяләүдәге хаталарны күрә белү сәләтен үстерү. Әсәрнең трактовкасындагы аерым образларны бозып күрсәтүче хаталарны ишетә, башкаруның автор стиленә, хикәяләүче образына туры килмәвен күрә белү сәләтен үстерү. Практик дәресләр.

Сәнгатьле уку өчен мөһим булган сыйфат, сәләт һәм күнекмәләр тәрбияләү. Эшнең эчтәлеге беренче һәм икенче укыту елларындагы кебек үк, бары тик бурычлар катлаулана һәм аларның үтәлешенә карата таләпләр күпкә арта.

**Тема 5. Практик дәресләр – 10 сәг.**

**Тема 6. Йомгамклау дәресе – 2 сәг.**

Нәтиҗәләр чыгару. Йомгаклау концерты.

**Программаны гамәлгә ашыруның оештыру-педагогик шартлары**

Материаль-техник тәэмин ителеш:

Занятиеләр санитар-гигиеник нормаларга( температура режимы, яктылык режимы һ.б.) туры килүче киң, җиллэтелгән бинада уздырылырга тиеш. Кабинет көзгеләр белән җиһазландырылырга тиеш. Дәресләрдә көзге күнегүләрнең дөрес үтәлешен тикшерү кирәк. Декорацияләр, костюмнар, грим кебек театраль атрибутиканың булуы да бик мөһим.

Мәгълүмати тәэмин ителеш:

Нәтиҗәле эш өчен фонотека, видеоматериаллар, күрсәтмә әсбаплар, укыту, фәнни-методик, диагностик, дидактик материаллардан файдалану, интернет технологияләре, укытуның техник чаралары: магнитофон, видеомагнитофон, телевизор, сәхнә һәм музыкаль материалларны эшкәртү өчен персональ компьютер куллану зарури.

Методик, дидактик тәэмин ителеш

Программаны уңышлы тормышка ашыру максатыннан түбәндәге дидактик материаллар эшләнде һәм кулланыла:

*Иллюстратив һәм демонстрацион материал:*

- сөйләм техникасы темаларына карата иллюстрация, репродукцияләр;
- тикшерелүче әсәрләр буенча буенча иллюстрацияләр;

*тарату материаллары:*

- “Тавыш өстендә практик эш” темасы буенча күнегү карточкалары;
- “Әсәрне яңгыраган сүздә гәүдәләндерү ” бүлегенә караган биремнәр белән карточкалар;

*программаны үзләштерүне тикшерүгә материаллар:*

- зачёт-дәресләр өчен биремнәр белән карточкалар, программа бүлекләре буенча имтихан-чыгышлар;
- иҗади биремнәр;
- “Әсәрне тикшерү” бүлеге буенча тестлар;
- кроссвордлар, викториналар һ.б.

**Әдәбият исемлеге**

**Педагог өчен әдәбият:**


1. Бантова М.А., Г.В.Бельтюкова, С.И. Волкова и др. «Школа России». Концепция и программы В 2 ч.- 4-е изд.-М.: Просвещение, 2009
2. Вахтель Н.М., Попова З.Д., Чарыкова О.Н. Практикум по выразительному чтению. Часть II: Учебно-методическое пособие. - Воронеж: Изд-во ВГУ, 2005. - 55 с.
3. Детская литература. Выразительное чтение. Практикум/ под. Ред. Т.В. Рыжковой.- учебное пособие для студентов средних профессиональных учебных заведений.- М.: Издательский центр «Академия», 2007.
4. Зайдман И. Н. Развитие речи и психолого-педагогичекая коррекция младших школьников.// Начальная школа. – 2003. - №6 – с. 5-14.
5. Кутявина С.В. «Универсальные поурочные разработки по литературному чтению» - М.:«Вако», 2006
6. Никитина Л.В. Повышение эффективности уроков чтения путем организации групповой работы. // Начальная школа. – 2001. - №5. – с99 101.
7. Павлова Л.А. Тренажер по выразительному чтению для учащихся 1-4 классов.- М.: Ювента, 2009.

8. Яценко И.Ф. «Поурочные разработки по внеклассному чтению».- М.: ВАКО, 2006
9. Р. Нуриев. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек.- Казан: 2000.- 152б.

**Укучылар һәм эти-әниләр өчен исемлек:**

1. Альбеткова Р.И. «Учимся читать лирическое произведение».- М.: «Дрофа», 2003
2. Орфоэпический словарь.- М.: Мир книги, 2003.
3. Фразеологический словарь русского языка.- М.: Дрофа, 2003.

**Кушымта.**

***Уку өчен репертуар***

*Беренче ел.*

**Тема 1. Халык авыз иҗаты.**
Тизәйткечләр, тел шомарткычлар. / Скороговорки.
Табышмак. / Загадки.
Санамышлар. / Считалки.
**Тема 2. Кышны яратабыз./ Любим зиму.**
Гульшат Зайнашева. Кыш. / Зима.
Амина Бикчантаева. Салкын саф һава. / Холодный свежий воздух.
Афзал Нигъматуллин. Беренче кар. / Первый снег.
**Тема 3. Тылсымлы сүзләр / Волшебные слова.**
Лябиб Лерон. Хәерле иртә! / Доброе утро!
Шаукат Галиев. Тыныч йокы! / Спокойной ночи!
Бари Рахмат. Рәхмәт. / Спасибо.
**Тема 4. Минем туган көнем / Мой день рождения**
Зиннур Хуснияр. Курчак алдылар миңа./ Мне купили куклу.
Музахит. Тутый кош./ Попугай.
Гүзель Исхакова. Куанычым./ Моя радость.
Творческая работа.
**Тема 5. Минем гаиләм / Наша семья**
Гулшат Зайнашева. Әбиемне яратам./ Люблю бабушку.
Бу бармак – бабай… / Этот пальчик – дед… (считалка)
Закия Туфайлова. «Әни» сүзе. / Слово «мама».
**Тема 6. Яз килә/ Весна идет**
Ахмет Ерикей. Тышта яз. / На улице весна.
Нури Арслан. Яз. / Весна.
Язгы авазлар. / Весенние звуки. По Г.Тукаю
**Тема 7. Матур җәй / Прекрасное лето**
Роберт Миннуллин. Болыт. / Облако.
Бари Рахмат. Су./ Вода.
Гамир Насрый. Зәңгәр күл. / Голубое озеро.
Проектная работа. «Любимое время года».

*Икенче ел.*

**Тема 1. Белем бәйрәме / Праздник знаний.**
Ринат Маннан. Исәнме, мәктәп! / Здравствуй, школа!
Бари Рахмат. Мәктәпкә./ В школу.
Михаил Пляцковский. Өйрәтәләр мәктәплярдә./ Учат в школе.
Барлас Камалов. Иң күңелле көн. / Самый веселый день.
Гульшат Зайнашева. Бер атнада ничә көн? / Сколько дней в неделе?
Творческая работа.
**Тема 2. Халык авыз иҗаты. Устное народное творчество.**
Табышмаклар. / Загадки.
Санамышлар. / Считалки.
Мәзәкләр. / Шутки.

**Тема 3. Көзге муллык. / Осеннее богатство.**
Лябиб Лерон. Яфрак бәйрәме./ Праздник листьев.
Айгуль Ахметгалиева. Көзге муллык. / Осеннее богатство.
Ахмет Ерикей. Уңыш./ Урожай.
Русская народная сказка. Репка./ Рус халык әкияте. Шалкан.
Г. Гараева. Көз һәм балалар җыры. / Осень и дети.
Шаукат Галиев. Витамин эзли. / Ищет витамины.
Ринат Маннан. Помидор егете. / Помидорчик.
Васима Хайруллина. Толымлы суган./ Лук с косичками.
Фанис Яруллин. Көзге табын. / Осенние яства.
Афзал Нигъматуллин. Алмагач һәм алма. Яблоня и яблоко.
Творческая работа.
**Тема 4. Туган илем / Родина моя.**
Равиль Файзуллин . Җир өстендә ниләр бар?/Что есть на земле?
Резеда Валиева. Иң матур җир. / Самое красивое место.
Ахмет Рашитов. Кояшлы ил – безнең ил. / Наша страна – солнечная страна.
Энже Муэминова. Туган ил. / Родина.
Татарстан – минем республикам. / Татарстан – республика моя. (из журнала «Салават күпере»).
Тематический тест.
**Тема 5. Кыш килде / Зимние забавы.**
Джават Тарземанов. Кыш. / Зима.
Закия Туфайлова. Кыш килде. / Зима наступила.
Галимзян Латыйп. Кыш шатлыклары. / Зимние радости.
Галимзян Латыйп. Яңа ел җыры. / Новогодняя песня.
Музахит. Яңа ел кайдан килә? /Откуда приходит Новый год?
Назиба Сафина. Кышкы җыр. / Зимняя песня.
Гасим Лотфи. Кар бөртекләре. / Снежинки.
Творческая работа.
**Тема 6. Безнең гаилә / Наша семья.**
Рафис Корбан. Атна көннәре. / Дни недели.
Габдулла Тукай. Безнең гаилә. /Наша семья.
Закия Туфайлова. Шофер булам. / Буду шофером.
Амина Бикчантаева. Дәү әнием. / Бабушка моя.
Рустем Мингалим. Крокодил күрдек. / Видели крокодила.
Айгуль Ахметгалиева. Безнең өйдә. / У нас дома.
Роберт Миннуллин. Уятыйм әле. / Разбужу-ка, я.
Хакимзян Халиков. Без ничәү? / Сколько нас?
Проектная работа. «Наша семья».
**Тема 7. Кошлар – канатлы дуслар / Птицы – крылатые друзья.**
Гасим Лотфи. Балалар ярдәм итә./ Дети помогают.
Гарафи Хасанов. Кошларга ярдәм. / Помощь птицам.
Фанис Яруллин. Чыпчык. / Воробей.
Шайхи Маннур. Исәнмесез, кошкайлар! / Здравствуйте, птички!
Гасим Латыйп. Тукран. / Дятел.
Музахит. Күгәрченнәр гөрлиләр. / Голуби воркуют.
Муса Джалиль. Күке. / Кукушка.
Афзал Нигъматуллин. Песи һәм чыпчык. / Кот и воробей.
Творческая работа.
**Тема 8. Яз килә / Идет весна.**
Равиль Файзуллин. Кар кызы кая киткән? / Куда уходит Снегурочка?
Амина Бикчантаева. Апрель ае. / Месяц апрель.

Марс Шабаев. Ташу. / Половодье.
Роберт Миннуллин. Яз керде өебезгә. / Весна пришла в наш дом.
Закария Ахмеров. Агачлар да авырый. / Деревья тоже болеют.
Юлдуз Шарапова. Тузганак. / Одуванчик.
Идрис Туктар. Витаминнар./ Витамины.
Хакимзян Халиков. Рәхмәт сезгә, ветераннар! / Спасибо вам, ветераны!
Рафис Гиззатуллин. Миләш нигә әче? / Отчего рябина кислая?
**Тема 9. Җәй / Лето.**
Гульшат Зайнашова. Без – табигать дуслары. / Мы – друзья природы.
Ильдар Юзеев. Гөл нигә шиңгән? /Почему цветок высох?
Амина Бикчантаева. Колын. / Жеребенок.
Гульшат Зайнашова. Сабантуй.
Ринат Мәннан. Яратмыйм. / Не люблю.
Габдулла Тукай. Бала белән Күбәләк. / Ребенок и бабочка.
Проектная работа. «Мы — друзья природы».
*Эченче ел.*
**Тема 1. Мин җәйне ничек үткәрдем?/ Как я провел лето.**
Дамир Гарифуллин. Август.
Эндже Авзалова. Көзге моңсулык. / Осенняя грусть.
Габдулла Тукайдан. Көз. /Осень.
Роберт Миннуллин. «К»лар тулган бакчага. / Огород полон «к».
Вакыф Нуриев. Китап. / Книга.
Газинур Морат. Туган тел. / Родной язык.
Каюм Насыри. Акыллы һәм яхшы холыклы. / Умный, да еще и добрый.
Творческая работа.
**Тема 2. Устное народное творчество.**
Табышмаклар. / Загадки.
Әкият эзләре буйлап. / По следам сказок.
Әкият-табышмак. Бүре, кәҗә, кәбестә. / Сказка-загадка. Волк, коза, капуста.
Санамышлар. / Считалки.
Мәзәкләр. / Анекдоты.
Мәкальләр. / Пословицы.
Тематическое тестирование.
**Тема 3. Кызык кызлар, малайлар / Смешные девчонки, мальчишки.**
Шаукат Галиев. Онытылган… / Забыл…
Ахмет Рашитов. Футболчы, имеш. / Подумаешь, футболист.
Ринат Маннан. Җиләк җыйганда. / Когда собирали ягоды.
Бари Рахмат. Бармаклар җитми. / Пальцев не хватает.
Муса Джалиль. Сәгать. / Часы.
Идрис Туктар. Ялкау өчен ботка суынган. /Для лентяя каша остыла.
Роберт Миннуллин. Малайлар сөйләшә./ Мальчики разговаривают.
Идрис Туктар. Авыраяк. / Копуша.
Творческая работа.
**Тема 4. Кыш, Яңа ел /Зима. Новый год.**
Фатих Хусни. Беренче кар. / Первый снег.
Виталий Бианки. Куян, Көртлек, Аю һәм Кыш бабай / Заяц, Куропатка, Медведь и Дед Мороз.
Габдулла Тукай. Җир йокысы. / Сон земли.
Абдулла Ахмет. Кышкы матурлык. / Зимняя красота.
Роберт Миннуллин. Чыршы әйләнәсендә. / Вокруг ёлки.
Творческая работа.
**Тема 5. Туган җирнең кадерен бел / Береги родную землю.**

Гумар Баширов. Нинди ул Татарстан? / Какой он Татарстан?
Равиль Файзуллин. Безнең КамАЗ. / Наш КамАЗ.
Роберт Миннуллин. Авыл малае белән шәһәр малае сөйләшкәне. / Разговор деревенского и городского мальчика.
Рашит Башар. Шәһәр төзим. / Строю город.
Эндже Авзалова. Бу гүзәллек яшәрме? / Сохранится ли эта красота?
Гариф Галиев. Туган ил кайдан башлана? / С чего начинается Родина?
Шаукат Галиев. Җирдә миңа ни кирәк? / Что мне нужно на Земле?
Анас Кари. Гөл янында. / У цветка.
Разиль Валиев. Зоопаркта. / В зоопарке.
Хакимзян Халиков. Ятим тургай. / Жаворонок-сирота.
Тематический тест.
**Тема 6. Минем туганнарым. Яз / Мои родственники. Весна**.
Роберт Миннуллин. Торам менә елмаеп. / Стою, улыбаюсь.
Резеда Валиева.  Туган көндә. / В день рождения.
Анас Хасанов. Сез ни әйтерсез икән? / А вы что скажете?
Фанис Яруллин. Кояштагы тап. / Пятно на  солнце.
В.Осеева. Бер әби ич. / Бабка.
Шаукат Галиев. Җиргә язны кем китерә? / Кто приносит весну?
Дардеменд. Кояш нурлары. / Солнечние лучи.
Творческая работа.
**Тема 7. Кечкенә дусларыбыз / Маленькие друзья.**
Гасим Лотфи. Батыркай / Смельчак.
Лиана Амирханова. Нәни дусларым. / Маленькие друзья.
Габдулла Тукай. Ташбака белән Куян. / Черепаха и Заяц.
Рафис Корбан. Пескәем. / Мой кот.
М.Галлямова. Дуслар. / Друзья.
Гумар Баширов. Песинең ял көне. / У кошки выходной.
Назип Мадьяров. Тукран. / Дятел.
Проектная работа. «Мой питомец».
**Тема 8. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл / В здоровом теле здоровый дух**.
Йолдыз Шарапова. Татарстан – спорт иле / Татарстан – спортивная страна.
Галимзян Гильманов. Универсиада.
Хакимҗан  Халиков. Хәрәкәттә  – бәрәкәт / В движении – сила.
Сания Ахметзянова. Үрнәк алыйк. / Возьмём пример.
Ахмет Ерикей. Чисталык сөябез. / Любим чистоту.
Вахит Монасыйпов. Шифалы табиблар. / Полезные врачи.
Марзия Файзуллина. Җәй житте. / Пришло лето.
Гариф Ахунов. Сабан туенда. / на Сабантуе.
Творческая работа.